**Украина мөселманнары Диния идарәсе**

*Шәйх ‘Абдуллаһ Әль-Һәрарий*

# Мохтасар

***Ислам Динендә иң кирәкле гыйлем***

***Имам Әбу Х̲әнифә мәз̲һәбе буенча***

***татар телендә***

الإرشاد

**«Әл-Иршәд»**

**Киев - 2005**

**Читайте наши книги:**

- Серия «Истинный путь» (Издание 2-е, исправленное и дополненное):
  - книга *1* — «Вера мусульманина».
  - книга *2* — «Таhарат».
  - книга *3* — «Намаз».
  - книга *4* — «Рамадан».
  - книга *5* — «Хадж».
  - книга *6* — «Закят».
  - книга *7* — «Путешествие и вознесение Пэйгамбэра».
- «Твердость в убеждениях».
- «Нравственность и культура в Исламе».
- «Мавлид Пэйгамбэра». О праздновании Дня рождения Пэйгамбэра.
- «Мухтасар» (содержит большинство из необходимых знаний по Исламу, как вопросы веры, мусульманское право (фикh), некоторые правила деловых отношений между мусульманами).
- «Истинный Путь» (содержит полное объяснение **‘акыда** (правильных убеждений и веры)).
- «Вопросы и Ответы» (содержит более четырехсот вопросов по религии и ответов к ним в объяснение книги “Мухтасар“).
- Серия «Детям о Кур’ане. История наших предков». (5 книг)
- Серия «Детям об Исламе. Исламская культура». (5 книг)
- «Избранные пятничные проповеди».
- «Осторожно, экстремизм».
- «Никах. Некоторые разъяснения вопросов бракосочетания по Шэригату».
- «Заблуждения ваhабитов» (источник краткой информации об этом течении, аргументов против опасности, которая исходит от него).



**Книга набрана и сверстана**
**издательством «Аль-Иршад»**
**при Духовном управлении**
**мусульман Украины**

**الإرشاد**

**По поводу любых вопросов, а также с замечаниями**
**и пожеланиями, обращайтесь в редакцию по адресу:**

✉ 02100 Киев-100, ул. Лукьяновская, 46
☎ (044) 274-09-16   Факс: (044) 456-17-70
E-mail: islam@i.kiev.ua

## Издание первое

Книга “Мухтасар”
на татарском языке

# МОХТАСАР

***Ислам Динендә иң кирәкле гыйлем***

***Имам Әбу Хәнифә мәзһәбе буенча***

**Язучы – Шәйх ‘Абдуллаһ Әль-һәрарий**

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

***Аллаһ Исеме белән изге эшләрне башлыйбыз,
Ул бу дөньяда – бөтен колларына рәхмәт бирүче, әмма
Ахирәттә – фәкать мөэмин-мөселманнарга гына.***

## КЕРЕШ СҮЗ

***Барча галәмнең Раббысы булган Аллаһыга мактау-шөкерләр булсын! Ул һичбер нәрсәгә мохтаҗ түгел, әмма без барыбыз да Аллаһыга мохтаҗбыз. Ул Үз мәхлүкатләре белән Үзе теләгәнчә хөкем итә.***

Бу китапның өйрәткәне – Ислам Динендә иң кирәкле мәглъүмәтләр бирелгән. Шул микъдарны белмәү ***мукялляф***[1] өчен мөмкин түгел.

Булар:

* ***гакыйдә*** – иман турында мәгълүмәтләр;

* ***фикһ***[2] (гыйбәдәть мәсъәләләре) – Ислам Дине Шәригъате кушкан әмерләр: ***Таһәраттән***[3] *башлап,* ***Хәҗ***[4] *гамәленә кадәр.*

* ***мөгамәләт*** – Әбу Хәнифә мәзһәбе буенча мөселманнар арасында булган кайсыбер мөнәсәбәтләр аңлатыла (сәүдә вә никәх кебек)

* ***гөнаһлар*** турында аңлатыла: йөрәк гөнаһлары, тел гөнаһлары вә башка әгъзалар гөнаһлары турында.

Шушы китап Әбу Хәнифә мәзһәбе буенча язылган.

Бу китапның исеме:

***"Хәнәфий мәзһәбе буенча Ислам Динендә иң кирәкле булган мәгълүмәтләрне өйрәтүче 'Абдуллаһ Әль-Һәрарийның Мохтасар китабы".***

---

[1] *Мукәлләф* – бәлигъ, акыллы, Исләм турында ишеткән кеше.
[2] *Фикһ* – Гыйбәдәть белән багълы булган Шәригать хөкемнәре.
[3] *Таһәрәт* – пакьлану, Истинҗә, Гөсел, Таһәрәт алу кебек.
[4] *Хәҗ* – Мәккә шәһәренә Кәгбә янына барып, гыйбәдәть кыйлу.

Изге гамәлләрегез кабул булсын өчен ошбу китапта бирелгән мәгълүмәтләргә күп игътибар итегез.

# БЕРЕНЧЕ БАБ

# ИҢ КИРӘКЛЕ ДИНИ МӘГЪЛҮМӘТЛӘР

## ИСЛАМДА ТАНЫКЛЫК СҮЗЛӘРЕ "ШӘҺӘДӘТЬ КӘЛИМӘЛӘРЕ"

Бөтен мүкәлләфләр Ислам Диненә керергә тиешләр вә Ислам Динен үлгәнче тотарга тиешләр. Ислам Дининең Шәригъатен үтәп. Исламда һәрбер мүкәлләф өчен лязем булган нәрсәләр арасында – ике ***Шәһәдәть кәлимәсен***[5] белү, мотлак ышанырга вә кеше ***кәфер***[6] булган булса – Ислам динен кабул итәр өчен Шәһәдәть кәлимәләрен шундук тел белән әйтергә тиеш. Әмма мөселман Шәһәдәть кәлимәләрен Намазда[7] әйтергә тиеш:

أَشْهَدُ أَن لا إِلهَ إِلاّ اللّهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّداً رَسُوْلُ اللّه ﷺ

/Әшһәдү әл-ля иляһә илляЛлаһ
үә әшһәдү әннә Мүхәммәдәр-расүлюллаһ/

“Мин беләм, йөрәгем белән ышанам, телем белән таныклык сүзләрен әйтәм: Аллаһтан башка тәңре юк, һәм мин беләм, йөрәгем белән ышанам, телем белән таныклык сүзләрен әйтәм: Мүхәммәд[8] – Аллаһның илчесе”.

**Шәһәдәть кәлимәләрнең мәгънәсе**

Беренче Шәһәдәть кәлимәсе:

أَشْهَدُ أَن لا إِلهَ إِلاّ اللّه

/Әшһәду әл-ля иляһә илляЛлаһ/

Мин беләм, йөрәгем белән ышанам, телем белән таныклык сүзләрен әйтәм: Аллаһтан башкасына гыйбәдәт кылырга дөрес

---

[5] Имам Әбү Хәнифә мазһабе буенча Әш-Шәһәдәтән шулай укыла:

أَشْهَدُ أَن لا إِلهَ إِلاّ اللّهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّداً عَبْدُهُ و رَسُوْلُهُ

Әшһәдү әл-ля иляһә илляЛлаһ үә әшһәдү әннә Мухаммәдән ‘абдүһү үә расүлюһ

[6] *кәфер* – имансыз.

[7] Имам Әбү Хәнифә мазһабе буенча Әттәхийятсез Намаз кабул була, әмма, гөнаһ языла, чөнки Әттәхийят хәнәфи мәзһәбендә – Важиб.

[8] Кем «Мухәммәд» исемен дөрес әйтәлмәсә: «Әбуль-Касим» дип әйтсен.

түгел, ягни Аллаһтан башка беркем дә гыйбәдәть кылу өчен лаек түгел.

Аллаһ – Бердән Бер Яралтучы. Барлыгы мәңге әүвәлсез вә ахырсыз. Ул – тере, бернәрсәгә дә һәм беркемгә дә мохтаҗ түгел. Ул – ризык бирүче, һәрнәрсә турында белүче, Кодрәте һәрнәрсәдән өстен, теләгән нәрсәне Яралтучы. Аллаһ теләгән нәрсә була, теләмәгән нәрсә һич булмый. Аллаһ ярдәм бирмәсә, кеше гөнаһтан саклана алмас, кеше гыйбәдәть кыла алмас[9].

Аллаһның иң бөек ***Сыфаты***[10] бар, Алар Аллаһыга гына лаек, вә Ул барча кимчелекләрдән өстен (пакь).

(لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَىْءٌ وَهُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ)

(Әш-Шура Сүрәсе, 11-нче Аять)

Аллаһы Тәгалә бер нәрсәгә дә охшамый вә Аның охшашы юк. Ул һәрнәрсәне ишетә вә һәрнәрсәне күрә.

Аллаһ – Мәңге бар, әмма Аллаһтан башка һәрнәрсә юктан бар булды, мәңге түгел, әүвәле бар. Аллаһ – Яралтучы, әмма Аллаһтан башка һәрнәрсә – мәхлүк, Аллаһның яралтылган нәрсәләр. ***Зәррәһтән***[11] башлап, ***Аль-‘Аршка***[12] тикле барча җанлы мәхлүкларны да, җансыз мәхлүкларны да – барысын Аллаһ яралтты. Барча гамәлләр: хәрәкәтләрне вә тик торуларны да Аллаһ юктан бар итте, хәтта ниятләрне, үзебезнең уйларыбызны, теләмиче башка керә торган уйларны да – барысын Аллаһ яралтты, Аллаһтан башка беркем дә аларны яралтмады. Ни табигать, ни бернинди сәбәп (гыйлләт) Яралтучы түгел. Һәрнәрсә Аллаһның Ирадәсе, Аның Кодрәте вә Тәкъдире белән, Аның мәңгелек Белеме белән барлыкка килде.

Аллаһ бөтен барлыкны юктан бар итте.

Коръәндә әйтелгән:

(وَخَلَقَ كُلَّ شَىْءٍ)

---

[9] Хәнәфи мәзһәбенең Имамы Әбу Җагфәр Әт-Тахәуий бу сүзләрне шулай аңлатты: Аллаһ сакламаса, кеше гөнаһтан саклана алмас, һәм Аллаһ ярдәм бирмәсә, кеше гыйбәдәть кыла алмас.

[10] *Сыфат* – Аллаһның исеме.

[11] *Зәррәһ* – иң кечкенә, бүленми торган нәрсә.

[12] *Әл-‘Арш* – Җәннәтнең түшәме, иң зур булган каты нәрсә, җисем.

(Әл-Фуркан Сүрәсе, 2-нче Аять)

Мәгънәсе: Аллаһ барча нәрсәләрне яралтты.

Аллаһ – Бердән Бер Яралтучы (юктан бар итүче).

Коръәндә әйтелгән:

( هَلْ مِنْ خَالِقٍ غَيْرُ اللّه )

(Фәтыр Сүрәсе, 3-нче Аять)

Ягъни: Аллаһтан башка Яралтучы юк.

Имам Ән-Нәсәфий әйтте:

[فإذا ضرب إنسانٌ زجاجًا بحجر فكسرهُ  فالضرب والكسر والإنكسار بخلق اللّه تعالى  فليس للعبد إلاّ الكسب  وأما الخلق فليس لغير اللّه].

/Фә-изә дорабә инсәнун зуджәджән бихәджәрин фәкясәраһу, фәд-дорбу үәль-кясру үәль-инкисәру бихъалькылляһи тә‘аля, фәляйсә лиль-‘абди илляль-кясб, үә әммәль-хъальку фәляйсә лигъайрилляһ/

Мәгънәсе: "Әгәр берәр кеше ташны пыялага ташлап аны ватса, аның ыргытуы да, ташның пыялага сугылуы да, пыяланың ватылуы да барысын Аллаһ яралтты. Кеше үз гамәлләрен кесеб итеп кенә тора, үзе бернәрсәне дә яралтмый. Аллаһтан башка бер кем дә яралта алмый".

Коръәндә әйтелгән: ( لَهَا مَا كَسَبَتْ وَعَلَيْهَا مَا اكْتَسَبَتْ )

/Ляһә мә кясәбәт үә ‘аляйһә мәктәсәбәт/

(Әль-Бакараһ Сүрәсе, 286 Аять)

Ягъни, мөселман кешегә яхшы эшләре өчен Аллаһ Тәгалә сәвап бирә, әмма яман эшләр кылса, аның өчен җәвап бирә (җаза алырга лаек).

Аллаһның Кәләмы мәңгелектә сөйләве, Аллаһның башка Сыйфаты кебек.

Чөнки Аллаһ мәхлүкатьларга һич охшамас, Заты да, Яралтуы да, Сыйфатлары да мәхлүкатьларга охшамый.

Залимнар[13] Аллаһыга төрле кимчелекләр кушалар. Барча кимчелекләрдән пакь булган Аллаһка мактау-шөкерләр булсын!

Элек әйтелгән нәрсәләрне Аллаһның Сыйфатларыннан 13 Сыйфаты тәсдикълай. Бу Сыйфатлар Коръәндә шул сүзләр белән һәм мәгънә белән йыш әйтелгән:

Аллаһның барлыгы.

Аллаһның берлеге.

Мәңге әүвәлсез.

Мәңге ахырсыз.

Үзе бар, башка беркемгә дә мохтаҗ түгел.

Кодрәт (беркем дә Аллаһка каршы баралмый).

Ирадәһ – һәрнәрсә Аллаһ теләсә була, теләмәсә – булмый.

Һәрнәрсәне белүче (әмма акыл вә зиһен белән түгел).

Һәрнәрсәне ишетүче (әмма колак белән түгел).

Һәрнәрсәне күрүче (әмма күз белән түгел).

Хәят (Тере, һич үлми).

Кәләм (Сөйләүче, әмма тел белән түгел).

Аллаһ бернәрсәгә дә охшамаган.

Бу Сыйфатлар диний китапларда, әсәрләрдә бик йыш очрый, шуның өчен галимнәр: "һәрбер мукалляф аларны белергә тиеш", – диеп әйттеләр.

Аллаһның мәңге бар булганын тәсдикълаганнан соң, Аның Сыйфатлары да мәңге бар булуы лязем диеп билгеле. Чөнки, кемнең сыйфаты мәхлүкъ булса – ул үзе мәхлүкъ була.

---

[13] *Залимнәр* – кәферләр, чөнки золымның иң яманы – көфер.

## Икенче шәһадәть кәлимәсенең мәгънәсе:

أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّداً رَسولُ اللّه

/әшһәдү әнна Мухәммәдәр-Расүлюллаһ/

Мин беләм, йөрәгем белән ышанам, телем белән тәсдикъ кылыйм: Мухәммәд – ‘Абдуллаһның улы, ‘Абдуллаһ – ‘Абдуль-Мутталибның улы, ‘Абдуль-Мутталиб – Һәшимның улы, Һәшим – ‘Абду-Мәнәфның улы, Курайш кабиләсеннән, салляллаһу ‘аляйһи үә сәллям, – Аллаһның колы вә кешеләргә һәм женнәргә[14] җибәрелгән Пәйгамбәре (Расүле). Ул ***Мәккәдә***[15] туган, Мәккәдә беренче Вәхий иңгән (Пәйгамбәрлек), аннан соң Аллаһның Әмерен үтәп ***Мединәгә*** һиҗрат кылды (күчте), шунда Ул каберенә куелды.

Шушы шәһадәть кәлимәсенең мәгънәсендә – иман итәргә тиешле ки: Аллаһ биргән бөтен Вәхийләрне Пәйгамбәребез тугъры, үзгәртмиче кешеләргә тапшырган.

Ул Вәхийләрдән – Кабер газабы вә Кабер рәхәтлеге, ике Фәрештә Мункәр һәм Нәкир кабердә сораулары, Бәъс (Кубарылу), Хәшр (Җыелу), Кыямәт (Ахирәт көне), Хисаб, Сәвап, Җәза, Шәфәгать, Мизан (Үлчәү), Сырат (Күпере), Хәүз (Күл), Җәһәннәм, Җәннәт, Әл-‘Арш (Җәннәт түшәме), Әл-Күрсий, Әл-Калям Әл-Әъля, Әл-Ляух Әл-Мәхфуз, мөселманнар Ахирәттә Җәннәттә күзләре белән шөбһәсез, шикелсез, урынсыз, тарафсыз, җиһәтсыз, Аллаһны күрерләр (в отличие от виденья созданного), мөселманнар Җәннәткә кергәч, анда мәңге калалар, әмма кәферләр Җәһәннәмгә кереп анда мәңге калалар, чыкмыйлар.

Аллаһның Фәрештәләре барлыгына ышанырга, Аллаһның Пәйгамбәрләренә, Мөкаддәс Китапларга, Тәкъдир (язмыш: яхшылык вә яман Аллаһның теләге белән була), һәм Мухәммәд

[14] *Җен* – уттан яралтылган мәхлүкатьләр.
[15] *Мәккә һәм Мәдинә* – Аравияда ике мөбәрак шәһәр.

– Пәйгамбәрләрнең иң соңгысы һәм барча Адәм балаларның иң яхшысы булганына ышанырга кирәк.

Һәм Мухәммәд Пәйгамбәр (‘аләйһиссәләм) Кыямәт Көненең галәмәтләре турында хәбәр иткән: Даджҗәл заһир булуы турында, Дәббәтүль-Әрд адлы хайван булуына, ике кавым Я’җүҗ вә Мә’җүҗ[16] чыгачак турында, күктән ‘Иса Пәйгамбәрнең (‘аләйһиссәләм) инәчәге, кояшның мәгрибтән (көнбатыш) яктан чыгачагы турында ышанырга кирәк.

Шулай ук ышанырга тиешле булган нәрсәләрдән: һәрбер Аллаһның Пәйгамбәре дугъры сөйләүче, гадел, акыллы, зиһенле.

Алардан берсе дә: ялганчы түгел, әшәке, акылсыз, зәгыйф зиһенле, хыянәт кылучы яки дивана була алмас.

Аларның һәрберсен Аллаһ көфердән, зур вә кечкенә әшәке гөнаһлардан саклады, хәтта Пейгамбәрлек килгәннән элек тә, гомерләре беткәнче.

Пәйгамбәрләр хата[17] эшләгән булсалар да, кешеләр үрнәк алганчы Үзләренә шунда ук Аллаһы Тәгаләдән тәүбә итәр өчен Әмер җибәрелгән булган.

Шуның нәтиҗәсе: Юсуф Пәйгамбәрнең кардәшләре әшәке гөнаһлар кыйлучы кешеләр булган өчен, Пәйгамбәр түгел иделәр, Биньяминнан башка. Әмма аларның токымыннан (калган нәселләреннән) Пәйгамбәрләр булганнар.

---

[16] Я’джудж и Ма’джудж – рус телендә аларга Гог-Магог дияляр.

[17] Хата, я дә әшәке булмаган кечкенә гөнаһлар.

## *КӨФЕР ТӨРЛЕЛӘРЕ*

Һәрбер мөселман үз хак Ислам динен (иманын) тотарга тиеш. Иманны боза торган, юк итә торган нәрсәләрдән сакларга, ягъни, диннән чыгудан сакланырга тиеш. Аллаһ безне шундый нәрсәләрдән сакласын!

Имам Ән-Нәүәүий һәм башка галимнәр шулай әйттеләр:

الردّةُ أفحشُ أنواع الكفر

Мәгънәсе: ***"Әр-риддәһ***[18] ***– көфернең иң әшәкесе***[19]***"***.

Әлеге заманда кешеләр арасында әйтелә торган сүзләргә әһәмият бирелми, игътибар ителми, хәтта күп кешеләр көфер сүзләрен сөйлиләр, аларны кулланганда үзләрен диннән чыккан дип уйламыйлар, ул сүзләрне галий диеп, гөнаһ диеп тә исәпләмиләр. Әмма кем андый сүзләрне әйткән булса – мөселман түгел.

Мухәммәд Пәйгамбәребезнең сүзләре шуны тәсдиклый:

{إِنَّ العَبْدَ لَيَتَكَلَّمُ بِالْكَلِمَةِ لا يَرَى بِهَا بَأساً يَهْوِي بِهَا فِي النَّارِ سَبْعِينَ خَرِيفا}

/Иннәль-`абдә ля-ятәкялляму биль-кялимәти ля яра биһә бә`сән яһуи биһә фин-нәри сәб`ыинә хорифән/

Мәгънәсе: “Дөреслектә, бәндә уйламыйча көфер сүзләрен әйткән булса, ул сүзләрдән зарар күрмәсә дә, шуның нәтиҗәсендә Җәһәннәм утына җитмеш көз[20] очып төшәр”.

Шул урын – Җәһәннәмнең төбе, ул фәкать кәферләр өчен.

Бу Хәдисне имам Әт-Тирмизий риваять итте, һәм бу Хәдискә ***хасан***[21] дәрәҗәсен бирде.

---

[18] *Ар-риддәһ* – кеше элек мөселман булып, аннан соң көфер эшләп Диннән чыгып кәфер булды.

[19] Иң әшәке – җирәндергеч, чөнки кеше мөселман иде, аннан соң Диннән чыгып кәфер булды, бөтен яхшы эшләре юкка чыкты, хакны батылга алыштырды. Әмма Дине инкяр итү, Аллаһа ышанмау – иң зур гөнаһ.

[20] Бу Хәдиста «җитмеш көз» – 70 ел.

[21] *Хәсән* – Хәдисның риваяте дөрес һәм ышанычлы икәнен аңлата.

Шундый ук мәгънәле Пәйгамбәребезнең тагын бер Хәдисы бар, аны Әл-Бухарий вә Муслим имамнар риваять иттеләр.

Хәдистән шушы мәгънә килеп чыга:

көфер сүзләрен әйтүче диннән чыккан була[22], һәм аңа шундый хәлләр ярдәм итми, гөзер булмый:

1) үзе әйткән көфер сүзләренең мәгънәсенә ышанмаса да;

2) үзе әйткән көфер сүзләрен хупламаса (риза булмаса) да;

3) үзе әйткән көфер сүзләр – көфер булганын (диннән чыгара икәнен) белмәсә дә.

Бу хәлләр берсе дә көфердән сакламый.

“Фикһ әс-сүннәһ” исемле китапны язган Египеттагы Сәгыйд Сәбик атлы кеше ялгыш фикерләрен язып, көфер турында дингә каршы булган сүзләрен әйтә.

Шулай ук кешенең ачуы чыгып та, көфер сүзләрен әйткән булса, барыбер бу хәлдә ул диннән чыккан була (кәфер була), аның ачуы гөзер түгел. Бу хәлне имам Ән-Нәүәүий аңлатты һәм әйтте:

[لوْ غَضِبَ رَجُلٌ عَلى وَلَدِهِ أوْ غُلامِهِ فضَرَبَهُ ضَرْبًا شَدِيدًا
فقال لهُ رَجُلٌ: ألسْتَ مُسْلمًا ؟ فقال: لا مُتعَمدًا كفر]

Мәгънәсе: “Әгәр бер кеше үзенең баласына я дә хезмәтчесенә ачуланып, аны каты кыйнаса һәм башка кеше: “син мөселман түгел мени?”, ә бу кеше сорауны аңлап: “юк” – диеп җавап бирсә, диннән чыккан була”. Бу хәлне ханәфий, шәфигый һәм башка галимнәр тәсдикълап әйттеләр.

Көфер өч төрлегә бүленә: игътикаддә, фигыйлдә һәм сүзләрдә. Аның турында ханәфий, шәфигый һәм башка галимнәр әйттеләр. Вә бу төрлеләр тагын күп төрлеләргә бүленә.

---

[22] Диннән чыгармый – 1) йоклаган вакытта сөйләсә; 2) теле ашыгып әйтергә теләмәгән сүз килеп чыкса; 3) үтерәләр дип куркытканда; 4) башка кешенең көфер сүзләрен накыл итеп: “фәлән кеше әйтте”, – диеп әйткән булса.

• **Беренче кысым** (игътикаддә): кем Аллаһның барлыгында шөбһә итсә, шикләнсә – кәфер була; Аллаһның Пейгамбәрендә шөбһә итсә, шикләнсә; Коръән мөкаддәс Китабы булуында шөбһә итсә, шикләнсә; Кыямәт Көне (Ахирәт көне) хаклыгында шөбһә итсә, шикләнсә; Җәннәт һәм Җәһәннәм хаклыгында шөбһә итсә, шикләнсә; Сәвап һәм Җаза (газәп) хаклыгында шөбһә итсә, шикләнсә; һәм шуңа охшаган барча галимнәр тәсдикълаган ("Бу – динебездә бар", – диеп), мәшһүр булган эшләрне инкәр итсә, шикләнсә – кәфер була.

Кем: "галәм яратылмаган, аның әүвәле юк", – диеп ышанса – кәфер була. "Мәддәсе әүвәлсез" – диеп әйтсә дә, "төзелеше - әүвәлсез", – дисә дә – дингә каршы була.

Барча галимнәр тәсдикълаган ("Ул – Аллаһның", – диеп) Аллаһның бергенә Сыйфатын инкәр итү – көфер, мәсәлән: Аллаһ һәрнәрсәне белгәнен инкәр итү.

Яки барча галимнәр тәсдикълап ("Ул – Аллаһыга лаек түгел", – диеп) Аллаһыга лаек булмаганны кушу, мәсәлән: җисем (тән).

Барча галимнәр тәсдикълаган ("ул – хәрам[23]", – диеп) хәрамга – "ул – хәләл[24]", – дию. Мәсәлән: зина кылу, ливат[25], хаксыз кешене үтерү, урлау, гасб[26] кылу.

Я дә мөселманнар арасында мәшһүр булган х̲әләлне – "х̲әрам", – дию. Мәсәлән: сәүдә, никәх.

Барча галимнәр тәсдикълаган ("ул – фарыз[27]", – диеп) фарызга: "ул – фарыз түгел", – дию. Мәсәлән: биш вакыт

---

[23] *Х̲әрам* – диндә ярамаган, гөнаһ.
[24] *Х̲әләл* – диндә яраган, рөхсәт ителгән.
[25] *Ливат* – арткы якка якынлык кылу.
[26] *Гасб* – көчләп кешенең малын алу.
[27] *Фарыз* – диндә лязем, кирәк булган эш.

Намазны, яки аның бер генә булса да ***Сәҗдәсен***[28], ***Зәкәтне***[29], Рамазан уразасын, Хаҗ, ***Удуу***[30].

Барча галимнәр тәсдикълаган ("ул – фарыз түгел", – диеп) хөкемгә, эшкә: "ул – фарыз", – дию.

Барча галимнәр тәсдикълаган ("ул – Шәригаттә бар", – диеп) ***Машру'иятне***[31] инкәр итү – көфер.

Киләчәктә көфер эшләргә тырышу, хәтта көфер кылар өчен ният итү, я да шушы бүлемдә әйтелгән нәрсәләрдән берсен эшләргә ният кылу, я да шунда шикләнү, тукталу – диннән чыгара.

Әмма кешенең теләмиче башка керә торган уйлар исәпләнми, аны хупламаса, йөрәккә кертмәсә – көфер түгел.

Кем: "Әбу Бәкр Пәйгамбәребезнең сахәбәсе булмаган", дисә – кәфер була, чөнки Корәндә аның турында әйтелгән.

Яки, барча галимнәр тәсдикълаган ("Ул – Пәйгамбәр булган", – диеп) Пәйгамбәрләрнең берсен булса да: " Ул Пәйгамбәр булмаган", дисә.

Я дә, барча галимнәр тәсдикълаган ("Бу хәреф – Коръәндә бар", – диеп) Коръәннең бер хәрефен булса да инкәр итсә ("Коръәндә бу юк", дисә).

Яки, барча галимнәр тәсдикълаган ("Бу хәреф – Коръәннең шул урынында юк", – диеп) Коръәнгә тагын бер хәрефне булса да өстәп кушу ("Коръәндә бу бар", дисә), гыйнәтлык[32] белән.

Кем Пәйгамбәргә Пәйгамбәрлек килүен инкәр итсә - мөселман түгел. Шулай ук Пәйгамбәрне мәсхәрәләсә, Аның исемен кимсетеп көлсә, мыскыл итсә.

---

[28] *Сәҗдә* – Намазда һәм башка гыйбәдәт кылганда җиргә иелеп тору.
[29] *Закят* – нисабы җиткән малдан өлешен чыгарып кирәкле кешеләргә өләшү.
[30] *Удуу* – Намаз уку, Коръән тоту һәм башка гыйбәдәт кылу өчен Тәһарәт.
[31] *Машру'ият* – Шәригаткә кергән хөкемнәр.
[32] *Гыйнәтлык* – тискәрелек.

Кем: “безнең Мухәммәд Пәйгамбәребездән соң башка берәр кемсә Пәйгамбәр булуы мөмкин”, дисә.

Аллаһның рахмәтеннән өметне кисү. Мәсәлән, кем: “Аллаһ һичбер гөнаһлы мөселманны гафу итмәс”, диеп әйтсә – кәфер була, чөнки Аллаһ Корәндә күп гөнаһкәр мөселманнарны гафу итеп, җәзаламас диеп вәгдә итте.

Яки: “Аллаһ һичбер гөнаһлы мөселманны газәпләндермәс” – дип уйлау – көфер, чөнки Аллаһ Коръәндә кайсыбер гөнаһкәр мөселманнарга җаза бирер диеп вәгдә итте. Кем Коръәнгә каршы килсә – диннән чыккан булыр.

Я дә, фәкат Аллаһ белгәне турында багучының[33] сүзләренә ышану (мәсәлән, Кыямәт Көне кайчан булуы турында).

• **Икенче кысым** (фигыйлләрдә): потка Сәҗдә кылмак, кояшка Сәҗдә кылмак.

Гыйбәдәть[34] итү нияте белән кешегә Сәҗдә кылу.

Әмма бер кеше икенче кешегә гыйбәдәт нияте белән түгел, хөрмәт итү өчен Сәҗдә кылса – диннән чыкмый, ләкин зур гөнаһ эшләгән була. Бу эш безнең Пәйгамбәребезнең Шәригатында хәрам, ә электәге Шәригатларда хәрам булмаган, мәсәлән: Фәрештәләр Пәйгамбәребез Адәм ‘Аләйһиссәләмгә хөрмәт өчен Сәҗдә кылулары билгеле.

Кайсыбер сихер белән шөгелләнгәннәр шайтанга Сәҗдә кылсалар – диннән чыккан булалар.

Яки мәсхәрә нияте булмаса да ***Мусхәфның***[35] кягазьләрен, битләрен чүплеккә ташлау, шулай ук өстенә диний мәглүмәтләр язылган нинди булсада кягазне чүплеккә ташлау, мәсәлән Аллаһның Исеме белән. Шулай ук Коръән Аятьләрен ***нәҗәсә***[36]

---

[33] *Багучы* – экстрасенс.
[34] *‘Гыйбәдәт* – табыну, буйсынуның иң бөек дәрәҗәсе.
[35] *Мусхәф* – Кор’ән китабы.
[36] *Нәҗәсә* – дин аңлаткан пычырак, кан, бук, сидек.

белән язу диннән чыгара, шуның кебек кан, сидек һәм башка нәрсәләрне даруланыр максаты кебек шифа булсын өчен куллану.

Олыглап көфер шигарларын[37] кию.

• **Өченче кысым** (сүзләрдә): алар бигерәк тә күп, мәсәлән: мөселманга “кәфер”, дию, яки: “яһүди”, “керәшен[38]”, “динсез[39]” “аның дине шундый” нияте белән, чагыштыру нияте белән түгел[40].

Кем Аллаһның бер Исемен булса да мәсхәра итсә. Аллаһның мөселманнарга вәгъдә иткән нәрсәләр өстеннән көлү, мыскыллау. Аллаһның кәферләрне газәп белән куркыту өстеннән көлү, мыскыллау.

Берәр кемсә: “әгәр Аллаһ миңа бернәрсәне үтәргә әмер итсә дә – аны кылмас идем” диеп әйтсә, кәфер булыр.

Шулай әйтсә дә: “Әгәр ***Кыбла***[41] тарафы үзгәрсә иде, шул якка Намаз кылмас идем” – көфергә төшкән була.

Яки гыйнәтлык, мәсхәра нияте белән: “Әгәр Аллаһ миңа Җәннәткә керергә нәсыйп итсә дә, шунда кермәс идем” – дисә.

Я дә шулай әйткән булса: “әгәр мин чирләгән вакытта Намазларымны укый алмасам, шуның өчен миңа Аллаһ җәза бирсә, Ул – залим”, дисә – кәфер була, чөнки Аллаһ залим түгел.

---

[37] *Шигар* – символ, аны кәферләрнең кабул булмаган әшәке табынуда куллана торган нәрсәләр, тәре кебек.
[38] *Керәшен* – христиан.
[39] *Динсез* – атеист, Аллаһка ышанмаган, динне танымаган кемсә.
[40] Кем мөселманга зур гөнаһлары сәбәпле чагыштыру өчен: «син – кәфер», дисә (“син кәфергә охшыйсың” димәктер) – бу эш зур гөнаһ, әмма көфер түгел. Ләкин кем ул сүзләрне чагыштырыр өчен түгел, туры әйтсә – кәфер була, чөнки мөселманның дине – көфер дип әйтү була.
[41] *Кыбла* – Намаз укыганда, Корбан чалганда Кә‘бә тарафына юнәлү.

Я дә берәр нәрсәгә: “бу Аллаһның теләге булмастан эшләнде”, дисә – шулай ук кәфер була.

Я дә шулай әйтсә: “әгәр миңа Пәйгамбәрләр яки Фәрештәләр, яки бөтен мөселманнар берәр нәрсә турында гуаһлык кылып ышандырырга теләсәләр дә – аларның шәһәдәтләрен, таныклык сүзләрен кабул итмәс идем”, – кәфер була. Я дә мәсхәрәләп: “бу эш ***Сөннәт***[42] булса да, аны эшләмәм”, яки шулай әйтсә: “Әгәр берәр кем Пәйгамбәр булса – аңа ышанмас идем”.

Я дә бер эшнең хөкемен галим әһеленнән сорап, дөрес җавабын белгәч, диний хөкемне кимсетеп: “Бу инде тагын нинди хөкем!”, дисә – кәфер була.

Кем әлеге вакытта булган “галимнәр” исемле кешеләр чыгарган ялгыш хөкемнәр турында сөйләгән вакытта аптырап: “Аллаһның ләгнәте барча галимнәргә булсын” – диеп, фәкать шул гасырда гына яшәгән кешеләрне күз алдында тотса, ниятләсә – кәфер булмас, әмма гөнаһтан котыла алмас, чөнки әле дә чын галимнәр җир йөзендә яшиләр, Хак Ислам динебезге өйрәтәләр.

Әмма бернинди галим турында сүз булмаган вакытта: “Аллаһның ләгнәте барча галимнәргә булсын”, дисә – кәфер була, вә соңыннан үзе: “мин барча галимне ләгнәт итмәдем”, дисә дә, аңа гөзер булмый, файда бирми, аңа шунда ук шәһәдәт кәлимәсен әйтеп, Исламга кайтырга тиеш.

Шуңа күрә: кем андый кешене “мөселман”, диеп уйласа – үзе Исламнан чыккан кәфер була, чөнки

Я дә: “мин Аллаһны, яки Фәрештәләрне, яки Пәйгамбәрләрне, яки Шәригатне, яки Исламны танымыйм”, – дисә, көфергә төшкән була.

Я дә Аллаһның хөкеменнән көлеп, кимсетеп шундый сүзләр әйтсә: “Мин шундый хөкемне белмим”, дисә – кәфер була .

---

[42] *Сөннәт* – Му<u>х</u>әммәд Пәйгамбәребезнең әйткән сүзләре, эшләре.

Яки, кәсәне тутырганда Коръәннең шушы Аятен укыса:

(وَكَأْساً دِهَاقاً)

(Сура Ан-Наба, Аят 34)

Бу Аяттә Җәннәт шәрабы белән тулы кәсә турында әйтелә.

Яки кәсә эчендә булганын түккәндә шушы Аятне укыса:

(فَكَانَتْ سَرَاباً)

(Ән-Нәбә’ Сүрәсе, 20-нче Аять)

Бу Аяттә Кыямәт Көнендә таулар ничек мираж кебек тетелерләр, юк булулары турында әйтелә.

Яки үлчәгән вакытта шул Аятне укыса:

(وَإِذَا كَالُوهُم أَوْ وَزَنُوهُم يُخْسِرُونَ)

(Сура Аль-Мутоффифин, Аят 30)

Бу Аяттә кайсыбер кешеләр мизан белән үлчәгендә һәм озынлык үлчәгәндә алдап, азайтып үлчәп бирү турында әйтелә.

Яки күп кешеләр җыелганын күреп шул Аятьне укыса:

(وَحَشَرْنَاهُمْ فَلَمْ نُغَادِرْ مِنْهُم أَحَداً)

(Сура Әль-Кәһф, Аят 47)

Бу Аяттә Кыямәт Көнендә барча җанлы бәндәләр бер урынга җыелу турында әйтелә.

Шул Аятьләрне укыганда Аларның мәгънәсеннән көлсә, яки кимсетсә, мәсхәрәләп укыса – диннән чыккан кәфер була. Шулай ук Коръәннең нинди булса да урынын мәсхәрәләп, кимсетеп укыган булса – ул кәфер була.

Әмма бу ният белән әйтелмәгән булса, андый кеше кәфер булмас, ләкин шейх Ә<u>х</u>мәд ибн <u>Х</u>әҗәр шулай әйткән:

لا تبعُدُ حرمتُهُ “Бу эш гөнаһка батудан ерак түгел”.

Кем Пәйгамбәрләрне яки Фәрештәләрне хурласа, сүксә – кәфер була.

Кем шул сүзләрне оялмастан әйткән булса: Намаз укый башласам – сутенер булырмын”, дисә – кәфер була.

Яки: “Намаз укый башлаганнан бирле бернинди яхшылык күрмәдем", дисә дә диннән чыккан була.

Кем мәсхәрәләп: “Намаз миңа килешми”, әйтсә, я дә мөселманга шулай дисә: “Мин синең дошманың вә синең Пәйгамбәреңнең дә дошманы”, яки ***шарифкә***[43]: “Мин сиңа дошман вә синең бабайыңа да дошман” (Пәйгамбәр турында уйлап), я дә шуңа охшаган яман сүзләр әйткән кемсә кәфер була. Бик күп мөселман галимнәре, мәсәлән ***факыһ***[44] Бәдр Ар-Рашид ханафий һәм Кадый ‘Ыяд маликий (Аллаһның рәхмәте үзләренә булсын), шул мәсьәләләр турында күп мисаллар китерделәр, шуңа күрә, аларны белергә кирәк, чөнки, кем гөнаһны нәрсә икәнен белмәсә – аны эшләүгә бик якын (ихтимал зур).

**Кагыйдә шундый**: ***һәрбер ышану, фигыйл яки сүз эчендә: Аллаһны, Аның мөкаддәс Китапларны, Расүлләрне, Фәрештәләрне, Дин хөкемнәрне, Мөселманнарга Рәхәтлек булуы турында вәгъдәләрне, гөнаһкәрләрне газап белән куркытуларны, мөселманнарның дини гыйбәдәтләрен мәсхәрәләү, кимсетү булса – барысы да кәфердер.***
***Шул нәрсәләр белән бик сак булыгыз! Якын да килмәгез!***

[43] *Шариф* – Пәйгамбәребезнең нәселеннән булган кеше.
[44] *Факыһ* – галим-гыбәдәт хөкемнәрен бик тирән белгән.

## *КӨФЕР БЕЛӘН БАГЛЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР*

Диннән чыккан һәркем шунда ук Шәһәдәт китереп, Исламга кайтырга тиеш, диннән чыгуының сәбәбен туктатып. Шул ук вакытта ул үкенергә тиеш, һәм башкача беркайчан да көфергә төшмәскә ният итәргә тиеш

Әгәр шул көфергә төшкән кеше Шәһәдәт китереп Исламга кайтмаса, аны ***тәүбәгә***[45] китерергә кирәк: бу кешене Исламга кире кайтаралар, я да аны ***Халиф***[46] тәүбәгә китерергә тырышып, бу кеше тыңламаса, аңа җаза бирелә. Халифка, ике тугры (дөрес) сүзле мөселман-шәһидләр тәсдиклап әйтсәләр, Халиф аларның сүзләренә таянып, хөкем кыла, яки диннән чыккан кеше үзе Халифка үз хәлен белдерсә.

Бу эш турында Имам Әл-Бухарий риваят иткән Пәйгамбәребезнең Хәдисендә аңлатыла.

Әгәр хатын кыз Ислам диненнән чыккан булса, аны Ислам free динен ә кире кайтканчы көчләп бикләп тоталар.

Кеше диннән чыккан булса, аның шул көндә тоткан уразасы бозыла, ***Таяммум***[47]***,*** Никәх – мөселман хатын белән кылынган булса да, христиан хатын белән кылынган Никәх булса да, яки яһүди хатын белән кылынган никәх – барысы да бозыла.

Ул чалган терелек (хайван, мал) хәрам, аны ашарга ярамый.

Шул кеше мирас малын алмый, аңа мирас күчми.

Ислам диненнән чыккан кеше өчен ***Җәназа***[48] укылмый, аны гөсел коендырмыйлар, ***кәфәнгә***[49]чорнамыйлар, киендермиләр вә мөселманнарның зиратларында, каберстанда күммиләр.

Ул диннән чыккан вакытында эшләп кәсеп иткән мал, мирас мөселманнарның “бәйт мал” – хазинәгә бирелә.

---

[45] *Тәүбә* – бу очракта Шәһәдәт кәлимәләрен әйтеп, Исламга кире кайту.

[46] *Халиф* – Халифатның башы – мөселман дәүләтнең патшасы.

[47] *Таяммум* – су кулланып булмаганда ком белән чистарыну.

[48] *Аль-джаназаһ* – үлгән мәселман өчен Намаз кылу.

[49] *Кяфан* – үлгән кешене чорнар өчен чүпрәк.